**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «29» апрель 2019 ел № 703

«Питрәч муниципаль районының Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 апрелендәге 601 номерлы карары белән расланган «Питрәч муниципаль районының Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:»

2. I бүлек I. 4 пунктының 8,9,14, 15 абзацларын; 5 бүлекнең 5.4 пунктын төшереп калдырырга

3. 3. 1 бүлекнең 1.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләүле хезмәтләрдән алынган акчаларның планлаштырылган күләмен куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Питрәч муниципаль районы Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры тарафыннан билгеләнә.

4. 2 бүлекнең 2.19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Квитанция формасы (ОКУД буенча форма 0504510) РФ ФМ 30.03.2015 ел, № 52н боерыгы белән расланган, Квитанция катгый хисап документы булып тора һәм аларны исәпкә алу «РФ Мәдәният министрлыгы карамагында булган оешмалар һәм учреждениеләр бланкларын куллану, исәпкә алу, саклау һәм юкка чыгару тәртибе турында методик күрсәтмәләр турында»15.07.2009 ел, 29-01-39/04 номерлы РФ Мәдәният министрлыгы хаты нигезендә алып барыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы А. Ф. Фазылҗановка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин